# Уральск

1895-1900 нче елларда Габдулла этисенең туганы Газизә апасы һәм җизнәсе Галиәсгар Госманов гаиләсендә яши. Монда Габдулланы "Мотыйгыя" мәдрәсәсенә укырга бирәләр, шул ук вакытта бала өч класслы рус мәктәбенә дә йөри.



# Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен ...

* 1900 нче елда җизнәсе үлеп киткәч, Габдулла бөтенләй мәдрәсәдә яши башлый.



Камил Төхвәтуллин  һәм Габдулла Тукай
 (1905 нче ел тирәсе)

# Уральск-Казан



**1901-1907 нче елларда Г. Тукай күп укый, күп эшли. Аның беренче әсәрләре “Әлгасрелҗәдит”, “Уклар”журналларында, “Фикер” газетасында дөнья күрә.**
**1907 нче елның көзендә Г.Тукай Казанга кайта. Танылган шагыйрьнең 1908-1910 нчы елларда балалар өчен илледән артык әсәре басылып чыга.**
**1908 нче елда Г.Тукай Г.Камал белән бергә “Яшен” сатирик журналында эшли,**
**1909 нчы елда “ Ялт-йолт” журналының редакторы була.**

**Уральск типографиясендә. 1905 нче ел**

# И Казан! дәртле Казан!
# моңлы Казан! нурлы Казан!



**Күңел белән сөям бәхтен татарның,**
**Күрергә шаһлыгын, тәхетен татарның.**
**Татар бәхете өчен мин җан атармын:**
**Татар бит мин, үзем дә чын татармын.**




**1912 нче ел**



**14 нче апрель, 1913 нче ел. Г.Тукайның соңгы сурәте**

**1913 нче елның**
**15 нче апрелендә**
**кичке 8 сәгать 15 минутта**
**татар халкының**
**бөек шагыйре**
**Габдулла Тукай**
**вафат була.**






# *Ел саен 26 нчы апрельдә Казанда*

## ***Шигырь бәйрәме үткәрелә.***

**Илаһи моң булып**
**шагыйрь гомере**
**Яңгырап тора шушы көнгәчә.**
**Ак сакаллы картлар**
**яшь Тукайга:**
**- Остазыбыз! – диеп эндәшә.**

**Нур Әхмәдиев**

# Кулланылган әдәбият


* Батулла Р. Кылдан нечкә, кылычтан үткен. – Казан, Татар. кит.нәшр., 1996
* Тукай Г.Избранное/ Габдулла Тукай; Перевод с татарского В.С. Думаевой-Валеевой. – Казань: Магариф, 2006. -239с.
* Тукай Г. Сайланма әсәрләр.Шагыйрь турында истәлекләр.- Казан: Татарстан Республикасы”Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2002. – 511б.
* Татарстан, 2006, №4
* Википедия